*…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!*

# Караш

1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.
№ 4 2015. Гыйнвар
«НӘШРИЯТ ЭШЕ» түгәрәге

*БУ АЙДА... предмет олимпиадаларының республика туры башланып китте. Район туры җиңүчеләренә алда тагы авыр сынаулар аша узасы. Барысына да уңышлар телибез!*

*БУ АЙДА... 25 нче гыйнварда 11 нче сыйныф укучылары математикадан сынау шартында имтихан тапшырдылар. Имтихан тапшыру пункты үзебезнең Лашман урта мәктәбендә булуы аерым игътибарга лаек. Гомумән, Бердәм Дәүләт имтиханнарын быелдан барысын да безнең мәктәптә уздырылачагы турында әйтелде. Шәпме? Белмим. Әмма шунысы билгеле: өйдә стеналар да булыша.*

*БУ АЙДА... Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан "Бөек Җиңүнең 70 еллыгына 70 "Бишле!" акциясе старт алды. Бу акциянең беренче атнасында ук инде унбиш "бишле" алган бишенче сыйныф укучысы Сафиуллина Зөһрә әлегә иң алда. Барысына да үҗәтлек, тырышлык телибез!*

*БУ АЙДА... тагы бик күп күңелле вакыйгалар булып узды, төрле спорт ярышлары. Алары турында алдарак!!!*

## "ОНЫТЫРГА ХАКЫБЫЗ ЮК!"



Ватан сугышы беткәнгә 70 елга якын вакыт узса да, сугыш хатирәләре тоныкланмый. Дошманга күкрәк киереп каршы торган, изге җиребезне саклап калган, аның иминлеге өчен гомерләрен дә кызганмаган каһарманнар һичкайчан онытылмас. Җиңү бәйрәмнәре тагын шаулап узар. Ләкин кешеләр йөрәгендә сугыш калдырган яралар һаман да сыкрый шул әле. Без халкыбызнның сугышта күрсәткән батырлык һәм фидакарьлекләрен, зур югалту һәм корбаннарын һич кенә дә истән чыгармаска тиешбез. Безнең авылдашыбыз Габдулла бабай Мөхәммәтшин бу сугыш афәтенең тере шаһиты. Нәкъ менә 9 нчы декабрьдә Лашман урта мәктәбендә уздырылган "Мәңге онытылмаслык хатирәләр" китабын тәкъдим итү кичәсендә ул кабат үткәннәрне хәтерендә яңартты. 17 яшеннән сугышка китеп, алгы сызыкта булулар, әсирлек җәфалары кичерүләр, чит илдәге армия хезмәте... Габдулла ага истәлекләре белән танышканда алар барысы да тере картина булып күз алдыннан уза. Габдулла бабай аны үзе дә күз яшьләрсез генә сөйли алмый. Ә сөйләргә кирәк. Яшь буын сугыш фаҗигасенең тирәнлеген аңласын; иреккнең, муллыкның кадерен белсен, күгенең аязлыгы өчен башларын салган сугыш корбаннарына рәхмәтле булсын өчен кирәк. Менә шуның өчен дә бу истәлекләрдән киләсе буынга әманәт итеп китап әзерләнде.



**_Лашман авылы җирлеге башлыгы. Р. Фәттахов Габдулла бабайга китапларны тапшыра._**

*Бу китап – буыннар бәйләнеше.*
*Бу китапта герой – гади кеше.*
*Бу китап - үткәнгә сәяхәт.*
*Бу китап – киләчәк буынга әманәт!*

## “ОНЫТЫРГА ХАКЫБЫЗ ЮК!”

Әлеге истәлекләрнең китап булып житешү тарихы да озын. Бөек Жиңүнең 65 еллыгына Габдулла бабайның оныгы Басыйр Нургатин башлап йөргән эш тукталып кала. Аның теләк-омтылышларын Басыйрның әнисе – Минегөл апа дәвам итә. Истәлекләрне әкренләп туплый, басмага жыя. Мәктәп музеена истәлеккә бирелгән бу язмалар миндә зур кызыксыну уятты. Ничек тә аларны киңрәк катлауга житкерәсе, таратасы килү теләге белән яндым. Авыл жирлеге башлыгы Рәвхать Габбас улы Фәттахов белән киңәшләшкәч, ул бу теләкне куәтләп алды. Бу истәлекләрнең китап булып житүенең материаль ягын үз өстенә алды. Инде менә ниһаять алар китап булып укучыга тәкъдим ителде. Биредә мажаралы сюжет та, текә геройлар да юк. Бу гади кешенең кичерешләре, гади кешенең тормыш юлы. Ләкин бу – чын тарих. Бернинди буяуларсыз, арттыруларсыз чын тарих. Бөтен илебезнең тарихы.

Китапны тәкъдим итү кичәсе дә бик үзенчәлекле булды. Галия Динмөхәммәтова житәкчелегендә укучылар белән әзерләнгән концерт номерлары да, кичәнең кунаклары сөйләгән чыгышлар да бик дулкындандыргыч иде.

Әйе, исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен бел, диләр. Шул вакытта гына дөньяда иминлек һәм тигезлек, узара дустанә мөнәсәбәтләргә омтылу көчлерәк, куәтлерәк булыр. Бер кичергән афәт, газаплар икенче шундый кичерешләрдән кисәтеп кала алсын иде. Әлеге китап безне кабат шуңа инандыра.



## !!!УЙЛАН!!!

Яшәп кара...

***Үләм, дисең. Ә менә син***
***Үлмичә кара яшәп.***
***Мамык мендәр урынына***
***Булса да салам түшәк,***
***Кемдер каймак ашаганда***
***Син каты кимерсәң дә,***
***Берәү шәраб чөмергәндә***
***Син суга тилмерсәң дә,***
***Кузгалак диеп капканың***
***Булса да яшел әрем,***
***Уртәлүнең соң чигендә***
***Тамса да күз яшьләрең,***
***«Булганына — рәхмәт!» диеп,***
***Ходайга әйтеп кара.***
***Яшәвеңнең бер мәгънәсез***
***Көннәре үтеп бара...***
***Булдырырсыңмы син шуны?***
***Булдырырсыңмы, Кеше?***
***Әллә инде «үләм» диеп***
***Бетерергәме эшне?! ...***
***Үләм, дисең. Ә менә син***
***Үлмичә кара яшәп.***
***Мең газаптан мең терелеп,***
***Бер гади булып, яшьнәп,***
***Сызланып кара яшәп...***

Халисә Ширмән - шагыйрә.

БЕЛӘСЕЗМЕ?

-Еланнарның 25 меңгә кадәр теше булырга мөмкин.

— Кешенең гомере буена коелган керфекләренең гомуми озынлыгы 30 метрга житә.

— Дөньяда һәр кешегә миллион кырмыска туры килә.

— Фил – сикерә белми торган бердәнбер хайван.

— Елан өч ел рәттән йоклый ала.

— Кеше елына уртача 1460 төш күрә

— Аю ат кебек үк тиз чаба ала.

— Сәгать ярым саен планетабызда бер тимер юл һәлакәте була.

## ШИГЪРИ ПОЧМАК

Сеңелемә

*Кичә минем сеңелем туды.*
*Исем таптык – Гөлсинә!*
*Гөлсинә дигән исемнәр*
*Бар дөньяга нур сибә!*

Безнең эт

Безнең йортта сакчы бар,
Уяу, акыллы бер эт.
Ул безгә бик булыша,
Өебезне саклаша.

Беренче укытучыма

Укытучы апам шәп!
Шаян һәм шундый әйбәт!
Мин әйтәм аңа рәхмәт,
Яратып һәм хөрмәтләп!

***Бүген шәп!***

***Бүген бәйрәм, бүген туй –***
***Апам китә кияүгә.***
***Бөтен өстәл сладости...***
***Барысы да в радости!***

*Бу матур кызны танийсызмы? Бу 5 нче сыйныф укучысы Айсылу Галиуллина. Уку алдынгысы, бик матур итеп җырлый, гомумән мәктәбебезнең иң булган кызларыннан. Ул әле тагын иҗат эше белән дә шөгыльләнә. Аның шигырьләрен, хөрмәтле укучыларыбыз, сезгә дә тәкъдим итәбез.*



*Ә Айсылуга иҗади уңышлар теләп калабыз.*

“Караш” газетасының әлеге саны өчен җаваплы: Газимзянова Р. Ф.